**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**КУБЯНСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Ул. Х.Такташа, д.1/1, село Кубян, 422740
Тел.: (8-84369) 36-3-39; факс: 36-3-39

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ КҮӘМ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Х.Такташ урамы., 1/1 нче йорт, Күәм авылы, 422740
Тел.: (8-84369) 36-3-39; факс: 36-3-39

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«29» гыйнвар 2021 ел. № 1

**Агач һәм куаклар кисүгә, кроньлауга яки утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ**:

1.Күәм авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 08.04.2013 ел, № 2 карары белән расланган « Агач һәм куаклар кисүгә , кронлаштыруга һәм утыртуга рөхсәт бирү буенча» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү:

**1.1. 2.6 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац һәм 2 пунктчасы белән өстәргә:**

"Мөрәҗәгать итүче әлеге регламентның 2.5 пункты белән мөрәҗәгать итә ала торган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе билгеләнгән. Мөрәҗәгать итүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган югарыда санап үтелгән документларны таләп итү тыела. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан югарыда күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган документларны тапшырмау мөрәҗәгать итүченең хезмәт күрсәтүдән баш тартуы өчен нигез булып тормый.

2) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар ,җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә ,аларны үтәү вакыты Россия Федерациясе законнары нигезендә килгән (авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш).»

**1.2. 2.8 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4 һәм 5 пунктчалар өстәргә:**

4) тиешле органга документлар тапшыру

5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булу.»

**1.3 3.4.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:**

«законнарны бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурычлар булу (булмау )турында мәгълүматлар.»

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында , Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб –адресы буенча ) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: (pravo.tatarstan.ru ) веб –адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Күәм авыл башкарма комитеты җитәкчесе Р. Р.Гатауллин